| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 30.03.2022. | № 387 |

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1859 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең киңәйтелгән утырышы эш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2022 елның 11 февралендәге РП-27 номерлы күрсәтмәләрен һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең 2022 елның 14 февралендәге МК-1 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1859 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3.2. пунктчасы белән тулыландырырга:

   «Ата-аналары Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре булган балалар өчен туклану бәясен, әлеге карарның 2 пунктында билгеләнгән түләүнең 50 проценты күләмендә билгеләргә».

   Әлеге ташлама Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге тарафыннан, хезмәткәрләр реестры нигезендә, Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә һәр ай саен, агымдагы айның 10 числосына кадәр, юлланыла».
2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Я[illegible]нага йөкләргә.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов